## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең Шүширмә төрак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**04 ноябрь, 2019** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 02 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2019 елның 04 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 2019 елның 04 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

а) авыл җирлеге территориясен төзеклэнлэндерү:
- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;
- Шүширмә авылындагы күперне ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу.
- Шүширмә авылында балалар мәйданчыгын төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;
- һәйкәлләрне төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;

б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:
- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

г) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны беренчел янгын куркынычсызлыгы чарасы белән тәэмин итүне оештыру:
- янгын сүндерү машинасын ремонтлау һәм техник запчастьләр сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 184 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -105, бу 57,0 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 105 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең Шүширмә торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:
- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;
- Шүширмә авылындагы күперне ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу.
- Шүширмә авылында балалар мәйданчыгын төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;
- һәйкәлләрне төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;

б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:
- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

г) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны беренчел янгын куркынычсызлыгы чарасы белән тәэмин итүне оештыру:
- янгын сүндерү машинасын ремонтлау һәм техник запчастьләр сатып алу
соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Борындык авыл җирлеге
Кайбыч муниципаль районы
Татарстан Республикасы
Совет рәисе урынбасары Р. Р. Нигъмәтҗанова